«Кайбыч таңнары»
№ 4 (9725) | **6 февраль** 2026 ел

Иң кайнар яңалыклар
**kaibicy.ru сайтында** 18+

Ватанпәрвәр

# Борындык Геройлары


## Тырыш уллары белән данлы авыл

**Кайбыч Геройлары турындагы мәкаләләр циклы дәвам итә. Аларның һәрберсе аерым темага багышланса да, Кайбыч ягының Геройларын тулы бербөтен күзаллау өчен искә төшерергә кирәк дип саныйбыз.**

"Геройларның даны мәңгелек" дигән баш астында беренче язма газетабызда әле 2025 елның декабрь аенда илленче номерда чыкты. Билгеле һәм билгесез Кайбыч ягы Геройлары турында мәкаләләр инде 2026 елның гыйнвар аенда беренче һәм икенче номерларда дөнья күрде. Ул язмаларда күренгәнчә, геройларыбыз бихисап. Мисал өчен, Олы Урсак һәм Олы Колаңгы авылларында икешәр Герой булырга мөмкин иде. Турминский авылында бер рәсми Герой булып та, икенчесе дә өстәлергә мөмкин булган. Ә менә Борындык авылында ике рәсми Герой бар. Әбрар Җәләлиевне дә искә алсак, әле өченчесе дә буласы булган бит!

Бу язма белән Кайбыч ягында тагын да күбрәк булган хезмәт Геройлары циклына керешәбез. Борындык авылында туып-үсеп, хезмәт иткән Барый Гарифуллин белән Рифкать Кәлимуллин икесе дә комбайнчы булган. Мөрәле МТСында эшләгәннәр. СССР Югары Советы Президиумының бер үк Указы нигезендә 1952 елның августында Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булалар. Болай булмый ич дип ничек сызып атмаганнар?

Барый абый 1907 елда туган. Укырга кереп, 1932 елда ук Мөрәле МТСында эшли башлый. Сугыш алдыннан, 1937-1941 елларда комбайнчы булып хезмәт итә. Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр диярлек яу кырында була, Варшава янында каты яраланып, туктап кала. Кайтып, яралары да төзәлеп бетмәгән килеш яңадан комбайнга утыра. Бу вакытта тракторга прицеп итеп тагып йөри торган "Коммунар" комбайннарында эшли. Бүгенге көн хезмәт җитештерүчәнлеге белән чагыштырып карау өчен саннар китерәм. 1951 елның кызган урак өстендә Барый Гарифуллин 25 көн эчендә 6249 центнер ашлык суктырып ала. Мин яшь чагында куәтле "Нива" комбайннары чыккач та, бу күрсәткечкә иң алдынгы игенче-механизаторлар гына ирешә ала иде. Ул вакытта, ягъни 75 ел элек, бу чын батырлык үрнәге була. Мондый күрсәткеч белән районда, республикада гына түгел, бөтен Советлар Союзы буенча алдынгылыкка ирешкәннәр.



Кайбер язмаларда Барый абый бала чагында Борындык мәдрәсәсендә дин сабагы алган диелә. Шулар нәтиҗәседер, узган гасырның туксанынчы елларында Барый Гарифуллин Борындык авылының имам-хатыйбы булып торды. Тарихи мәчетне халыкка кайтаруда төп рольне үтәде. Уфа каласына мөфти Тәлгать Таҗетдин янына барып җитеп, ярдәм дә, рөхсәт тә алып кайтты. Күкрәгенә "Алтын Йолдыз" таккан мулланы күргәч, башкалар нәрсә уйлагандыр. Без Барый абыйга соклана да, аның белән горурлана да идек. Аллаһы Тәгалә озын гомер биреп, ул 2003 елның декабрь аенда 96 яшендә вафат булды. Ике Герой да Борындык зиратында күмелде. Бөек якташларыбызның урыннары җәннәттә булсын.



Рифкать Кәлимуллин 1927 елда туган. 1941 елда ул комбайнчы ярдәмчесе булып эшкә урнаша. Мөрәле МТСының атаклы директоры Григорий Улитин, 15 яшьлек егеткә ышаныч күрсәтеп, "Коммунар" комбайнын мөстәкыйль егәрләргә рөхсәт бирә. Дөресен әйтергә кирәк, киләсе 10 елда олы җитәкче һәм талантлы, тырыш егет бер-берсенә нык таянып эшлиләр. Рифкать абый Тукай кебек була. Яшь-яшь килеш зур ачышлар ясый, рационализатор була. Ургыч-жатканы киңәйтү хисабына гади комбайнның уру-сугу мөмкинлекләрен арттыра. Сугыштагы кебек армый-талмый эшләүне кушкач, гаять зур хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешә. Бөтен илгә танылган комбайнчы була. Бер генә мисал китереп үтәсем килә. Рифкать абый күбрәк Кошман кырларында эшли. Ул вакытта "Коммунар" комбайнының саламын, ике хатын-кыз утырып, сәнәк белән төртеп торган. Шуларның берсе Кошман кызы Саимә апа Камалиева була. Бу хакта бер очрашуда Саимә апа үзе сөйләде. Урып-җыюның кызган вакытында өч тәүлек туктаусыз, ялсыз эшләдек, диде. Чык төшкәч, ниһаять, кайтып йокларга җыенган идем, Рифкать абый мотоциклына утырып төшеп җитте, тагын эшкә керештек, диде. Мотоцикл дигәннән, кыш көне Рифкать абыйның аны аэрочана итеп йөрүе, тирә-якта беренче булып җил эффектына таянып генератор ясавы һәм электр энергиясен куллануын сөйлиләр. Шулай хезмәт итә торгач, Рифкать Кәлимуллинның дәрәҗәсе дә нык күтәрелә. 1949 елда, 22 яшендә, аңа беренче Ленин ордены бирелә. Кирәк бит! Инде киләсе 1950 елда ук, яшь егет икенче Ленин орденына лаек була. Ә менә 1951 елгы эш нәтиҗәләре буенча, 1952 елда Рифкать Кәлимуллинга Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә. "Алтын Йолдыз" белән беррәттән, күкрәгенә өченче Ленин ордены тагыла. Сугыштамы, хезмәттәме, Ленин орденына кыска срокта лаек булган тагын күпме Геройларны беләбез?!

Кызганыч, мин Рифкать абый белән очраша алмадым. Район аерылган елларда 66 яшендә вафат була ул. Шулай да юлларыбыз кисешкән булып чыкты. Ул кандидатлык диссертациясен 1966 елда Мәскәүдә, Тимирязев академиясенең мин укыган инженерлар институтында яклый. 80 нче еллар башында шул ук институтта докторлык диссертациясен якларга да йөри ул. Илебезнең атаклы инженер-галимнәре югары бәя биргән булалар. Бу инде мин үзем шунда укыган еллар. Яңа, зур, көчле комбайннар уйлап ясау чоры иде ул. Кызганыч, Рифкать абыйга никтер диссертациясен якларга мөмкинлек бирмиләр. Шуңа карамастан, Татарстан халкы күңеленә ул Хезмәт Герое, галим-практик булып кереп калды.

Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Рифкать Кәлимуллин исемендәге күчмә кубок булдырып, озак еллар аны ярыш алдынгыларына тапшырып барды.

Кайбыч комбайнчылары – Рифкать һәм Барый абыйларның дәвамчылары да еш кына бу призны алды. Хәзер дә районыбыз игенчеләре, мул уңышлы кырларда рекордлы күрсәткечләргә ирешеп, фидакарь хезмәт итүләрен дәвам итә.

**Рәмис Хәялиев,**
**Олы Кайбыч**

## Якташыбызның исеме кире кайтты

Патриот

Фирәдә **Батталова**

**Күптән түгел редакциягә Яшел Үзән шәһәреннән эзтабар Рәхимулла Гарифуллиннан чираттагы хат килеп ирешә. Анда Бөек Ватан сугышында катнашкан якташыбыз турында хәбәр ителә.**

Рәхимулла ага "Тагын бер фронтовик турында мәгълүматлар табылды. Ул — 1907 елда Олы Кайбыч авылында туган Сәлим Кәлимулла улы Халитов", – дип язган һәм аның туганнарын табарга булышуны сораган.

Эзләнүләр безне Бакча урамындагы йортка алып килде. Анда 90 яшьлек Ягъфәр Халитов — Сәлимнең туганнан туган энесе яши. Аларның әтиләре Кәлимулла белән Сәлимулла бертуган булганнар. Зур гаиләдә тугыз бала үсә, алар илнең төрле почмакларына тарала. Еллар буе хатлар аша сакланган элемтә әкренләп өзелә. Сәлим Халитов Кыргызстан якларына ничек барып чыккан соң— эш эзләпме, гаилә корыпмы? Анысы билгесез. Гаиләсе, балалары булу-булмавы да мәгълүм түгел.

Ә менә Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Үзәк архивында аның хәрби юлын тасвирлаучы документлар саклана. Алар Сәлим Халитовның 1944 елда шәхси батырлыгы өчен өч тапкыр югары бүләкләргә лаек булган кыю солдат икәнлеге турында сөйли.

35 яшьлек Сәлим Халитов Бөек Ватан сугышына Кыргызстаннан китә. Ул 1942 елның 6 гыйнварында Кыргыз ССРның Ош өлкәсе Сүлүктү (Сулюкта) хәрби комиссариаты тарафыннан армиягә алына. 1942 елның 1 июленнән сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Ел ярымнан соң, 1943 елның 1 декабрендә яралана, ләкин яңадан сафка баса.

Сәлим Халитов икенче Белоруссия фронты составындагы 194 нче Речица Кызыл Байраклы укчы дивизиясенең 616 нчы укчы полкында хезмәт итә. Бу полк күп кенә каты сугышлар аша үтә, Калуга оборонасында мөһим роль уйный, дошманга зур югалтулар китерә. Дивизия составында 616 нчы полк сугышчылары елганы кичә, Холстово көньягындагы юлны кисә һәм алга баруын тәэмин итә, Серпухов өчен барган бәрелешләрдә катнаша.

1944 елның сентябренә кадәр полк 48 нче армия составында була. Бу армия башта Белоруссия, аннары Балтыйк буе фронтларында сугыша. Күрсәткән батырлыгы өчен кече сержант Халитов 1944 елның 22 февралендә "Батырлык өчен" медале белән бүләкләнә, шул ук елның 28 августында бу бүләккә кабат лаек була.

Якташыбызның чын батырлыгы турында 1944 елның 5 октябрендә гвардия подполковнигы Даневич имзалаган бүләкләү кәгазе сөйли. Анда 616 нчы укчы полк пулемётчысы, кече сержант Сәлим Халитовка Кызыл Байрак ордены бирү турында язылган.

"Иптәш Халитов 1944 елның 1 июленнән 10 сентябренә кадәр барган сугышларда күп тапкырлар батырлык һәм кыюлык үрнәкләре күрсәтте. Кырыктан артык гитлерчыны юк итте. 1944 елның сентябрендә Нарев елгасына якынлашканда дошманның яхшы итеп ныгытылган оборона чиген өзгәндә, пулемёт уты белән укчы бүлекләргә немец траншеяларын алырга ярдәм итте, дошманның ике контратакасын кире какты", — диелә документта.

194 нче укчы дивизия 1939 елның сентябрендә Себер хәрби округында, Новосибирск өлкәсендә төзелә. 616 нчы укчы полк аның төп бүлекләренең берсе була. Калуга оборонасында ул, 470 нче укчы полкның 3 нче батальоны белән бергә, дошман һөҗүмен тоткарлаучы төп көчкә әверелә. Бер сугышта полк елганы кичә һәм, Холстово көньягындагы юлны ябып, дивизиянең алга баруын тәэмин итә.

Барановичи–Брест юнәлешендә һөҗүмне дәвам итеп, армия гаскәрләре, 65 нче һәм 28 нче армияләр белән берлектә, өч көнлек сугышларда Барановичи районындагы дошман төркемен тар-мар итә. Июль ахырына Сураж шәһәре көньягындагы районга чыгалар. Август-сентябрь башында, сугышып, якынча 150 чакрым юл үтәләр һәм 8 сентябрьгә Ружаны- Пултуск чигендә Нарев елгасына барып җитеп, оборонага күчә.

1944 елның 22 сентябрендә армия икенче Белоруссия фронты составына кертелә. 1945 елда аның гаскәрләре Көнчыгыш Пруссия стратегик операциясендә катнаша, Фришес-Хафф култыгына чыга һәм Балтыйк диңгезе ярында һөҗүм алып бара. Җиңүдән соң армия берникадәр вакыт Польшада калып, территорияне бандформированиеләрдән чистарту бурычларын үти, 1945 елның сентябрендә таратыла.

Сәлим Кәлимулла улы Халитовның соңгы хезмәт урыны 102 нче укчы дивизиясе була.

Мәкалә әзерләнгәндә район мәгариф бүлеге начальнигы, Сәлим Халитовның ерак туганы Илмас Хәмидуллин геройның тулы исеме Сәлимулла булуын хәбәр итте. Аның әнисе Фатыйма исемле, Кәрибулла һәм Нәбиулла исемле абыйлары, Зәйнәп һәм Галия исемле апалары булган. Шулай ук аның 70 яшькә кадәр яшәве һәм Ташкент шәһәрендә вафат булуы билгеле булды. Бәлки, әлеге язмадан соң орденлы кече сержантның башка туганнары да табылыр. Аларның редакция белән элемтәгә керүләрен сорыйбыз.

Бөек Ватан сугышы солдатының тагын бер исеме туган якка — туган җир хәтеренә, гаилә тарихына һәм халык батырлыгы елъязмасына кире кайтты.